СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 134** **“21” август 2019 ел**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 51 номерлы «Җир салымы турында '' карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Шушмабаш авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 51 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,08 процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан гына үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов